**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ XIII СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р №75**

Мөслим авылы «14» декабрь 2021 ел

**2022 елга Мөслим муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Уставының 37 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елга Мөслим муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Күрсәтелгән мөлкәтне хосусыйлаштыру ысулын Мөслим муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мөслим муниципаль районы Башлыгы урынбасары А.М. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Мөслим муниципаль районы
Башлыгы урынбасары,
Мөслим муниципаль районы
Советы рәисе урынбасары

А.М. Әхмәтҗанов

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Советының 2021 елның
14 ноябрендәге 75 нче номерлы
карарына 1 нче кушымта

## 2022 елга Мөслим муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)

1. Торак булмаган бина – бозаулар урыны
   Төзелгән елы: 1960 ел.
   Гомуми мәйданы: 790,2 кв.м.
   Адресы: Татарстан Республикасы, Мөслим муниципаль районы, Иске Карамалы авыл җирлеге

2. Торак булмаган бина – сыерлар урыны
   Төзелгән елы: 1970 ел.
   Гомуми мәйданы: 1397,3 кв.м.
   Адресы: Татарстан Республикасы, Мөслим муниципаль районы, Иске Карамалы авыл җирлеге